# ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл жирлеге Чәкән торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

**13 октябр 2023 ел** **№2**

2003 елнын 06 октябрендәге 131-03 номерлы «Россия Федерациясендэ җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге Чәкән торак пунктында гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. 2024 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, гаиләләре махсус хәрби операциягә юнәлтелгән гаилә әгъзасыннан тыш, Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Чэкэн торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә узара салым кертергэ.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл иту буенча тубәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

1) Чекан торак пунктыдагы урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, урамнарны яктырту җайланмасы;

2) Чекан торак пунктындагы рус һәм татар зиратыы территориясен төзекләндерү, киртәләр урнаштыру, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү;

3) Чекан торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

4) Чекан торак пункты халыкның күпләп ял итү урыннарын, аларга якын урнашкан территорияләрны төзекләндерү.

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Вахитов авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге башлыгы: Г.И. Аскарова